**Татар телендә урта гомуми белем бирү мәктәбенең**
**9 нче сыйныфында укучы татар балалары өчен**
**татар теленнән үткәрелә торган республика олимпиадасының**
**муниципаль этабы өчен биремнәр**
**(2014/2015 нче уку елы)**

I. Тестлардан берәр дөрес җавапны билгеләгез.

1. *Халкыма* сүзе нинди аваз үзгәреше кичергән?
   а) ассимиляция;
   ә) редукция;
   б) диссимиляция;
   в) протеза.

2. *Һичшиксез, борынгы, төнбоек* сүзләре кайсы орфографик принципка нигезләнеп языла?
   а) тарихи-традицион;
   ә) фонетик;
   б) морфологик;
   в) график.

3. Сузык авазларның төрләре ягыннан аерылып торган сүз кайсы җөмләдә?
   а) Лилия үзенә күлмәк тегә;
   ә) Зөбәрҗәт өйдә әнисенә булыша;
   б) Егет кеше иптәшенә ярдәм итә;
   в) Сез өйдә нинди эшләр эшлисез?

4. Әйтелеше белән язылышы туры килмәгән сүзләр рәтен билгеләгез.
   а) хезмәт, нәтиҗә, хөрмәт;
   ә) тупланган, сакланмыйча, мәкальләр;
   б) нинди, мәзәкләр, хәзинәбез;
   в) дәрәҗәдә, такмаза, байлыгы.

5. *Каракныкын бур урлаган* мәкалендә нинди сүзләр кулланылган?
   а) аваздаш сүзләр;
   ә) капма-каршы мәгънәле сүзләр;
   б) мәгънәдәш сүзләр;
   в) тамырдаш сүзләр.

6. Фразеологик әйтелмәләрдән генә торган рәтне билгеләгез.
   а) авыз еру, уртак тел табу, борын чөю;
   ә) базарга бару, чыбыркы шартлату, көтү куу;
   б) дөрес юл табу, хәзинә табу, җавап табу;
   в) күккә күтәрелү, ерактан күрү, яшәүне ярату.

7. Омонимның төрен билгеләгез.
*Һаман артыр, чигеннән дә ашар ул,*
*Кибәрсең син, йөрәк бәгърең ашар ул*. (Г.Тукай)
   а) омограф;
   ә) омофон;
   б) омоформа;
   в) саф лексик омоним.

8. Ономастика ул – ...

а) ялгызлык исемнәрне өйрәнә;
ә) сүзләрнең килеп чыгышын өйрәнә;
б) сүзләрнең мәгънәсен өйрәнә;
в) телдәге тотрыклы сүзтезмәләрне өйрәнә.

9. Кайсы сүзләр башкаларыннан аерылып тора?
1) борыч, 2) бормалы, 3) борау, 4) боргыч, 5) борчак, 6) борылыш, 7) борма

а) 2, 4;
ә) 1, 5;
б) 3, 7;
в) 2, 6.

10. Бирелгән җөмләдә ясалма нигезле ничә сүз бар?
*Бу вакыйгалардан соң берничә көн узгач, Тукайның кәефе яхшыргач, аның бүлмәсенә Фатих Әмирхан бер шәп кыяфәтле татар баен алып керде.* (Р.Б)

а) 4;
ә) 5;
б) 6;
в) 3.

11. Мөнәсәбәт белдерүче модальлек кушымчалары гына булган рәтне билгеләгез.

а) –са/-сә, -ып/-еп, -ачак/-әчәк;
ә) -ды/-де, -сыз/-сез, -чы/-че;
б) –рак/-рәк, -кай/-кәй, -шар/-шәр;
в) –лар/-ләр, -ган/-гән, -да/-дә.

12. *Балакай-бәләкәй, гамәл-әмәл, күз-күр, хикәят-әкият* сүзләре сүз ясалышының кайсы ысулына карый?

а) сүз ясагыч кушымчалар ялгану;
ә) сүзләрнең аваз составын үзгәртү;
б) бер сүз төркеменнән икенчесенә күчү;
в) сүзләрне кушу.

13. Җөмләдә билгеләнгән сүзгә дөрес морфологик анализны билгеләгез.
*Татарча да **яхшы** бел,*
*Урысча да **яхшы** бел...* (Ш.Маннур)

а) рәвеш, күләм-чама рәвеше, гади дәрәҗәдә, җөмләдә рәвеш хәле, тамыр сүз;
ә) сыйфат, гади дәрәҗәдә, җөмләдә рәвеш хәле, тамыр сүз;
б) рәвеш, саф рәвеш, гади дәрәҗәдә, җөмләдә хәл, тамыр сүз;
в) сыйфат, гади дәрәҗәдә, җөмләдә аергыч, тамыр сүз.

14. Бәйлекләр белән теркәгечләр генә булган рәтне күрсәтегез.

а) таба, ләкин, бәлки, мөгаен;
ә) дөрес, әмма, өчен, имеш;
б) һәм, саен, әгәр, ахры;
в) шикелле, сыман, гәрчә, кебек.

15. *Алсу, бүлмәсенә керү белән,*
*Өске киемен салып ташлады;*
*Ватык көзгесенә **карый-карый***
*Карлы чәчен сүтә башлады* (Һ.Такташ)
җөмләсендә билгеләнгән сүз –

а) хәзерге заман хикәя фигыль;
ә) саф рәвеш;
б) хәл фигыльнең II төре;
в) хәл фигыльнең I төре.

16. *дөм* кисәкчәсе кайсы сүз белән артыклык дәрәҗәсендәге сыйфат ясый?
а) тиле;
ә) надан;
б) сукыр;
в) ялгыз.

17. Иярчен җөмлә баш җөмләгә 2 төрле юл белән бәйләнә. Бирелгән җөмләгә икенче төрле юл белән бәйләнгән синоним җөмлә языгыз.
*Яхшы картлар юк урында яхшы яшьләр дә булмый* (Адыгей мәкале)

18. Кайсы җөмлә исем җөмлә?
а) *Туган җирең – Идел буе,*
*Һәр телнең бар туган иле* (Н.Нәҗми);
ә) *Бөрчекләнеп торган кара туфрак, эсседән кипкән ефәк үлән һәм ефәк чуклы кылганнар, кылганнар...* (Ә.Еники)
б) *Кайгылар теле түгел син,*
*Шатлыгым теле бүген* (Х.Туфан)
в) *Күп телләрне белү – яхшы шөгыль,*
*Туган телең үги калмаса..* (Р.Фәйзуллин)

19. Аерып бирелгән сүз нинди җөмлә кисәге?
*Үзе **юкның** күзе юк* (М).
а) ия;
ә) аергыч;
б) хәбәр;
в) хәл.

20. Җөмләнең төрен билгеләгез.
*Ул яңадан күзен ачканда, юлдаш абыйлар юк, ат нindидер авыл урамы буйлап бара иде* (Ә.Фәйзи)
а) тиңдәш түгел иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә;
ә) катнаш кушма җөмлә;
б) иярченле кушма җөмлә;
в) бер-бер артлы ияр үле катлаулы кушма җөмлә.

## II. Теоретик бирем.

Мөстәкыйль сүз төркеме буларак сыйфат

## III. Гамәли бирем

*Шәһәрнекеләр, киемнәре бик әйбәт булса да, дәресләрен бер дә Хәлимнән артык белмиләр*. (И.Гази)
1. Тыныш билгеләрен куярга.
2. Җөмлә чикләрен билгеләп, бәйләүче чараларны күрсәтергә.
3. Җөмлә кисәкләренең асларына сызарга.

4. Җөмләнең схемасын сызарга, төрен билгеләргә.
5. *Әйбәт* сүзенә фонетик анализ ясарга.
6. *Хәлимнән, белмиләр, бик* сүзләренә морфологик анализ ясарга.
7. *Дәресләрен* сүзен төзелеше һәм ясалышы ягыннан тикшерергә.

## IV. Иҗади бирем

Бирелгән мәкальләргә нигезләнеп, сөйләшү әдәбе турындагы фикерләрегезне 8-10 җөмләдән артмаган бәйләнешле текст итеп язызгыз.

Һәрбер сүзнең урыны бар.
Башта уйла, аннан сөйлә.
Сөйли белсәң, тыңлый да бел.
Олылар сүзен бүлдермә.
Сүздә тору – зурлык, сүздә тормау – хурлык.